ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.06.2023 Олы Кайбыч ав. №268

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминиятләштерү фонды турында» 2022 елның 14 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 августындагы 1415 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Башкарма комитетының түбәндәге карарларына:

«Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 30 сентябрендәге 407 номерлы;

«Милеккә җир кишәрлекләре бирү хокукы булган затлар сыйфатында исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 30 сентябрендәге 408 номерлы;

«Шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасында булган белешмәләрне, документларны, материалларны күрсәтү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 30 сентябрендәге 404 номерлы;

«Мәгълүмат тактасын урнаштыру, вывескаларны урнаштыру дизайн-проектын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 30 сентябрендәге 405 номерлы;

«Каникул вакытында балаларның ялын оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 17 декабрендәге 506 номерлы;

«Өстәмә гомуми белем бирү программаларын, шулай ук спорт әзерлеге программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларына кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау

турында» 2021 елның 23 декабрендәге 513 номерлы;

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының махсуслаштырылган торак фонды составына һәм составын төшереп калдыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 26 гыйнварындагы 20 номерлы;

«Муниципаль мөлкәт реестрыннан исәпкә алу объектлары турында мәгълүмат бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2022 елның 26 гыйнварындагы 21 номерлы;

«Җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектын саклап калу эшләрен башкаруга бирем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 26 гыйнварындагы 22 номерлы;

«16 яшькә җиткән балигъ булмаганнарга никахлашуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 26 гыйнварындагы 23 номерлы;

«Авиация эшләрен башкаруга, парашют сикерүләргә, һава судноларының демонстрацион очышларына, пилотсыз очу аппаратларының очышларына рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 26 гыйнварындагы 24 номерлы;

«Җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектын саклап калу эшләрен башкаруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 26 гыйнварындагы 26 номерлы;

«Муниципаль милектәге су объектларын су объектларыннан файдалану шартнамәсе яисә су объектын файдалануга бирү турындагы карар нигезендә файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 26 гыйнварындагы 27 номерлы;

«Мондый шартнамәне төзү хокукына торглар нәтиҗәләре буенча муниципаль милектән түләүсез файдалану шартнамәсен төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 26 гыйнварындагы 28 номерлы;

«Муниципаль милектәге җирләрдә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 26 гыйнварындагы 29 номерлы;

«Социаль наем шартнамәсе буенча бирелгән муниципаль торак фондының торак урыннарын алмаштыру документларын рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 26 гыйнварындагы 31 номерлы;

«Муниципаль торак фондының торак урыннарын гражданнар милкенә тапшырганда документларны рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 26 гыйнварындагы 32 номерлы;

«Муниципаль мөлкәтне арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау, торглар үткәрмичә түләүсез файдалану турында» 2022 елның 26 гыйнварындагы 33 номерлы;

«Хезмәт урыны наем шартнамәләре буенча муниципаль торак фондында гражданнарга торак урыннары бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 26 гыйнварындагы 35 номерлы;

«Муниципаль милектәге һәм арендага бирү өчен билгеләнгән күчемсез мөлкәт объектлары турында мәгълүмат бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 26 гыйнварындагы 36 номерлы;

«Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан файдаланучыларга автомобиль юлларының торышы турында мәгълүмат бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 26 гыйнварындагы 37 номерлы;

«Элек хосусыйлаштырылган торак урыннарны муниципаль милеккә кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 26 гыйнварындагы 40 номерлы;

«Җир кишәрлеген сатып алу турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 26 гыйнварындагы 41 номерлы;

«Җир кишәрлегеннән даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукын яисә җир кишәрлегенә гомерлек мирас итеп биләү хокукын туктату турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 26 гыйнварындагы 42 номерлы, 3.3.2.1 пунктының 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«Формалаштырылган гарызнамәнең формаль-логик тикшерү гариза бирүченең һәр кырын электрон формадагы кырны тутыру процессында орган (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә автомат рәвештә бердәм портал тарафыннан гамәлгә ашырыла. Бердәм портал белән тутырылган кырның корректлы булмаган электрон формасы ачыкланганда, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны юкка чыгару тәртибе турында мөрәҗәгатьнең электрон формасында ук мәгълүмат аша хәбәр ителә.».

2. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 19 июлендәге 267 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. кушымтаның 2.6.1 пунктында «Россия Федерациясе пенсия фонды» сүзләрен «Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминләштерү фонды» сүзләренә алмаштырырга;

3. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Индивидуаль торак төзелеше объекты яисә бакча йорты параметрларын планлаштырылган төзү турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объектының яисә бакча йортының билгеләнгән параметрларына һәм индивидуаль торак төзелеше объектын яисә җир кишәрлегендә бакча йортын урнаштыруның мөмкин булуы хакында хәбәр итү юнәлешендә муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау

турында» 2021 елның 28 июлендәге 293 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

кушымтаның 2.5.1. пунктында «индивидуаль торак төзелеше объектын төзү яисә реконструкцияләү» сүзләрен «Индивидуаль торак төзелеше объектын төзү, реконструкцияләү (күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп, индивидуаль торак төзелеше объектларын төзүдән яисә реконструкцияләүдән тыш)» сүзләренә алмаштырырга.

4. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау, элек бирелгән рөхсәтләрне юкка чыгару турында» 2021 елның 28 июлендәге 296 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

кушымтаның 2.8.2 пунктының 6 пунктчасында «5.1, 5.6, 5.7 өлешләре» сүзләрен «реклама конструкциясен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең гомуми мөлкәте кулланылса, 5 өлеш, 5.1, 5.6, 5.7 өлешләре белән» сүзләренә алмаштырырга.

5. «Муниципаль милектәге җир кишәрлегенә карата сервитут (гавами сервитут) билгеләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 июлендәге 298 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.8.1. кушымтаның 6 пунктындагы 6 пунктчасында «, линия объектлары булып торучы инженерлык корылмаларына капиталь ремонт ясау максатларында гавами сервитут билгеләү очрагыннан тыш, шулай ук мондый инженерлык корылмаларының кишәрлекләренә (өлешләренә) капиталь ремонт ясау максатларында» сүзләрен өстәргә.

6. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Бакча йортын торак йорт һәм торак йорт бакча йорты дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 30 июлендәге 304 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.8.2 пунктына түбәндәге эчтәлекле 8 пунктча өстәргә:

«8) бакча йортын су басу, су керү зонасы чикләрендә урнашкан җир кишәрлегендә урнаштыру (бакча йортын торак йорт дип тану турындагы гаризаны караганда).».

7. «Җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 30 июлендәге 321 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

кушымтаның 2.8.3.2 пунктының 13 пунктчасында «бакчачылык» сүзен «гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык алып барулары» сүзләренә алмаштырырга.

8. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Социаль наем шартнамәсе буенча торак урын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 30 сентябрендәге 406 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

8.1. 3.3.2.1 пунктының 11 абзацын кушымталарны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган гарызнамәнең формаль-логик тикшерү гариза бирүченең һәр кырын электрон формадагы кырны тутыру процессында орган (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә автомат рәвештә бердәм портал тарафыннан гамәлгә ашырыла. Бердәм портал белән тутырылган кырның корректлы булмаган электрон формасы ачыкланганда, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны юкка чыгару тәртибе турында мөрәҗәгатьнең электрон формасында ук мәгълүмат аша хәбәр ителә.»;

8.2.кушымтаның 2.6.1 пунктының 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) социаль түләүләрне алу турында белешмәләр - Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминләштерү фонды;».

9. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль милектәге җир кишәрлеген бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 30 сентябрендәге 410 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

9.1. 2.8.2 пунктының 13 пунктчасында кушымтада «бакчачылык» сүзен «гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык алып барулары» сүзләренә алмаштырырга

9.2. 3.3.2.1 пунктының 11 абзацын кушымталарны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган гарызнамәнең формаль-логик тикшерү гариза бирүченең һәр кырын электрон формадагы кырны тутыру процессында орган (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә автомат рәвештә бердәм портал тарафыннан гамәлгә ашырыла. Бердәм портал белән тутырылган кырның корректлы булмаган электрон формасы ачыкланганда, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны юкка чыгару тәртибе турында мөрәҗәгатьнең электрон формасында ук мәгълүмат аша хәбәр ителә.».

10. «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2022елның 26 гыйнварындагы 39 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

10.1. 2.6.1 пунктының 11 пунктчасын кушымталарны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11) фамилия-исем төркеменең, туу датасының, җенесенең һәм СНИЛСның туры килүен тикшерү - Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминиятләштерү фонды;»;

10.2. 3.3.2.1 пунктының 11 абзацын кушымталарны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган гарызнамәнең формаль-логик тикшерү гариза бирүченең һәр кырын электрон формадагы кырны тутыру процессында орган (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә автомат рәвештә бердәм портал тарафыннан гамәлгә ашырыла. Бердәм портал белән тутырылган кырның корректлы булмаган электрон формасы ачыкланганда, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны юкка чыгару тәртибе турында мөрәҗәгатьнең электрон формасында ук мәгълүмат аша хәбәр ителә.».

11. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2011 елның 30 маендагы 177 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

12.Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда бастырырга.

13. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Петухова Ф.Ф.га йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров